РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Староматакского сельского поселения Алькеевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Иске Матак авыл жирлеге
Советы

Адрес: 422890, РТ, с. Старые Матаки,
ул. Центральная , 4
тел: : 8 (84346) 79-2-12

Адресы: 422890, РТ, Иске Матак авылы,
Центральная ур.,4
факс: 8 (84346) 79-2-12

**РЕШЕНИЕ** Иске Матак авылы **КАРАР**

**2015 елның 29 гыйнвары** **120№**

Административ хокук бозулар буенча беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге турында

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы, 2010 елның 30 июлендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Әлки муниципаль районының Иске Матак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Үз компетенциясе чикләрендә Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.6, 3.2, 3.4, 3.6, 3.7, 4.4 статьяларында һәм 19.4 статьясындагы 1 өлешендә, 19.4.1 статьясындагы 1 өлешендә, 19.4.1 статьясындагы 1 өлешендә, 19.5 статьясындагы 1 өлешендә, 19.7 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы административ комиссиясенең җаваплы секретарено билгеләнгән рәвештә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затларга хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр, җирле үзидарә органнарына хисап тапшырырга.
3. Әлеге карарны Әлки муниципаль районы Иске Матак авыл җирлеге мәгълүмат стендында урнаштырырга.

Әлки муниципаль районы
Иске Матак авыл җирлеге башлыгы: Н.И.Кудряшов

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Иске Матак авыл җирлеге
Советының 2015 елның 29 гыйнварындагы
120 номерлы карарына кушымта

**Үз компетенциясе чикләрендә Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.6, 3.2, 3.4, 3.6, 3.7, 4.4 статьяларында һәм 19.4 статьясындагы 1 өлешендә, 19.4.1 статьясындагы 1 өлешендә, 19.4.1 статьясындагы 1 өлешендә, 19.5 статьясындагы 1 өлешендә, 19.7 статьясында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге**

| АХБтК статьялары | Вәкаләтле вазыйфаи зат |
|---|---|
| **ТР АХБтК 2.6 статьясы**<br>Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәве<br><br>**ТР АХБтК 3.2 статьясы**<br>Урам сәүдәсен оештыру тәртибен бозу<br><br>**ТР АХБтК 3.4 статьясы**<br>Урамнарны, квартал эчендәге яктыртуны тоту кагыйдәләрен бозу<br><br>**ТР АХБтК 3.6 статьясы**<br>Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрне, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу<br><br>**ТР АХБтК 3.7 статьясы** | Авыл җирлеге башлыгы<br><br>Иске Матак авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе<br><br>Иске Матак авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибы |

| | |
|---|---|
| Этләрне урамда йөрү тәртибен бозу<br><br>**ТР АХБтК 4.4 статьясы**<br>Муниципаль милектәге торак булмаган фонд объекты белән эш итү һәм күрсәтелгән объекттан файдалану тәртибен бозу<br><br>РФ АХБтК 19.4 статьяның 1 өлеше Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы орган вазыйфаи затының законлы күрсәтмәсенә буйсынмау, муниципаль контроль<br><br>РФ АХБтК 19.4.1 статьяның 1 өлеше Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы, муниципаль контроль органы вазыйфаи затының законлы эшчәнлегенә комачаулау<br><br>РФ АХБтК 19.5 статьяның 1 өлеше Дәүләт күзәтчелеген (контроль) гамәлгә ашыручы органның (вазыйфаи затның) законлы күрсәтмәсен (карарларын, күрсәтмәләрен) вакытында үтәмәү, муниципаль контроль<br><br>РФ АХБтК 19.7 статья Мәгълүмат (белешмә) тапшырмау | |